2006 ел, 9 июнь 293

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Тљзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре” турында 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Тљзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре” турында 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

“Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасының Тљзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турында нигезләмәнең 3.1, 3.2 нче пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.1. Министрлык түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашыруда җаваплы:

архитектура эше белән идарә (01.04*);

шәһәр төзелеше белән идарә (01.05*);

төбәк әһәмиятендәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү (01.05.2*);

шәһәр төзелешен проектлау буенча төбәк нормативларын әзерләүне тәэмин итү (01.05.3*);

калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру белән идарә (01.06.09*);

муниципаль милектәге ГТКларның куркынычсызлык мәсьәләләреннән гайре, Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмаларның (ГТК) иминлеген тәэмин итү белән идарә (01.06.10*);

билгеләнгән тәртиптә, торак-коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә бәяләрне (тарифларны) көйләү (01.09.02.1*);

иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен тәэмин итү (01.16*);

төзелеш материаллары сәнәгате белән идарә (03.01.06*);

төзелеш белән идарә (03.01.09*);

билгеләнгән тәртиптә, гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм кулланучыларга сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән идарә (04.01*), шул исәптән торак, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү базарын формалаштыру өчен шартлар тудыру (04.01.01*);

гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү белән идарә (04.01.02*);

Татарстан Республикасы милкендәге торак фонд белән идарә (04.01.05*);

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабыннан социаль-мәдәни өлкә объектларын капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләүне үткәрү эшчәнлеге белән идарә (01.04.06*).

3.2. Министрлык үз вәкаләтләре кысаларында түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Икътисад һәм сәнәгать министрлыгы белән – түбәндәге вазыйфаларны башкарганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

дәвамлы вакытка социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.1*);

макроикътисадый программалаштыру (01.01.1.1*);

дәвамлы вакытка төбәкләр буенча программалаштыру (01.01.1.2*);

дәвамлы этапка тармак буенча программалаштыру (01.01.1.3*);

планлаштырыла торган елга социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.2*);

планлаштырыла торган елга гомумикътисадый программалаштыру (01.01.2.1*);

планлаштырыла торган елга төбәк буенча программалаштыру (01.01.2.2*);

планлаштырыла торган елга тармак буенча программалаштыру (01.01.2.3*);

территория буенча планлаштыру схемасын һәм Татарстан Республикасының территория буенча планлаштыру схемасын реализацияләү планын эшләүне тәэмин итү (01.05.1*);

бирелгән вәкаләтләр кысаларында бәяләрне (тарифларны) көйләү (01.09*);

табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеген көйләүне һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруда катнашу (01.09.1*);

бирелгән вәкаләтләр кысаларында җитештерү әһәмиятендәге продукциягә, товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны) көйләү (01.09.02*);

инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә (01.10*);

инновация эшчәнлеген үстерү белән идарә (01.11*);

Татарстан Республикасының белем бирү учреждениеләреннән һәм алар барлыкка китергән фәнни оешмалардан гайре, фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә (01.12.02*);

энергия һәм ресурсларны саклау белән идарә (01.14*);

дәүләти мәгълүмат ресурсларын булдыру белән идарә (01.15.01*);

Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләти мәгълүмат ресурсларын булдыру белән идарә (01.15.01.2*);

ведомство карамагындагы предприятиеләр буенча сәнәгать белән идарә (03.01*);

электр энергетикасы белән идарә (03.01.01*);

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән – түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының дәүләти мәгълүмат ресурсларын булдыру белән идарәдән гайре, Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә (01.15.02*);

дәүләти мәгълүмат ресурсларын булдыру белән идарәдән гайре, дәүләти мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә (01.15.02*);

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән – түбәндәге эшләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының бюджет процессы һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә (01.02.1*);

бюджетара мөнәсәбәтләрне көйләү (01.02.3*);

Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән – бирелгән вәкаләтләре кысаларында табигый ресурсларны файдалану, әйләнә-тирә табигый мохитне саклау өлкәсендә идарәне гамәлгә ашырганда (01.06*);

Татарстан Республикасының Хезмәт һәм мәшгульлек министрлыгы белән – түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашырганда:

хезмәткә түләүне, хезмәт мөнәсәбәтләре, турыдан-туры хезмәт белән бәйле мөнәсәбәтләрне көйләү (01.13.01*);

хезмәтне саклау белән идарә (01.13.02*);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән – түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендә чараларны оештыру һәм үткәрү белән идарә (02.01.01*);

муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә идарә (02.01.02*);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә (02.01.03*);

бирелгән вәкаләтләр кысаларында мобилизация әзерлеге белән идарә (02.01.05*);

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән – билгеләнгән тәртиптә, федераль белем бирү учреждениеләрендә ала торган белем бирүдән гайре, өстәмә һөнәри белем бирү белән идарәне гамәлгә ашырганда (04.05.08*);

Татарстан Республикасының Социаль яклау министрлыгы белән – түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашырганда:

инвалидларның тереклек эшчәнлеген тәэмин итү белән идарә (04.06.04*);

халыкның аерым категорияләренә социаль ярдәм белән идарә (04.06.06*);

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге мөлкәт белән идарә (01.07*);

Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез милек (биналар, корылмалар), транспорт, җиһазлар, мәдәни мирас объектларын файдалану белән идарә (01.07.01*);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән – социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләти мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарәне гамәлгә ашырганда (01.15.02.1*)”;

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.6 һәм 3.3.7 нче пунктчалар өстәргә:

“3.3.6. Җирле үзидарә органнары белән муниципаль үсеш фондыннан, социаль чыгымнарны финанслашуның төбәк фондыннан субсидияләрне җирле бюджетлар тарафыннан файдалану нәтиҗәлелеге бәясе индикаторлары турында килешүләр әзерли һәм төзүне тәэмин итә.

3.3.7. Җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга бирелгән торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә кайбер дәүләт вәкаләтләренең үтәлешен (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган индикаторларны формалаштыру һәм тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру сыйфатын чагылдыручы индикаторларның әһәмиятенә ирешүне тикшерүдә тоту юлы белән) тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра”.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры Р.Н.Миңнеханов

F:\KARAR\358130бз3.doc